РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422054, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы, Саба районы, Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР
09.11.2020 №12

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 30 нчы апрелендә кабул ителгән 9 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы Карар кылды:
1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 30 нчы апрелендә кабул ителгән 9 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт ечен түләү шартлары турында " гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече теркеме белгеченең вазыйфаи окладын 11 498 сум күләмендә расларга.»;
1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карарның гамәлен 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга
3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына 2020 елның 1 октябреннән, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, яңа штат расписаниеләрен расларга.
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының
2020 елның 9 ноябре 12нче номерлы карарына
1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 15759 |
| Депутатлар | 11498 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 11498 |